Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

2 август 2021 ел № 3

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы җирлеге территориясендә гражданнарның беренчел хәрби исәбен оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында» Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы башкарма комитетының 2021 елның 8 июнендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Борискино авылы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы җирлеге территориясендә гражданнарның беренчел хәрби исәбен оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында» Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы башкарма комитетының 2021 елның 8 июнендәге 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтада:

1 бүлекнең 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Хәрби-исәпкә алу хезмәткәрләрен вазыйфаларына билгеләү, күчерү һәм эштән азат итү Әлмәт муниципаль районы һәм шәһәр хәрби комиссары белән килештереп башкарыла.

3 бүлекнең 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы башкарма комитетына беренчел хәрби исәпкә алу һәм броньлау буенча көндәлек эшчәнлектә, запаста булучы гражданнарны, Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы башкарма комитетында эшләүчеләр саныннан тәэмин итәргә».

4 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

«IV. ХОКУК

4.1. Планлы һәм максатчан эш алып бару өчен хәрби исәпкә алу хезмәткәре хокуклы:

федераль дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасы

субъектының башкарма хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оештыру-хокукый формаларына һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә учреждениеләрдән һәм оешмалардан кирәкле материаллар һәм мәгълүмат соратып алу һәм аларны билгеләнгән тәртиптә алу буенча тәкъдимнәр кертергә;

Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы җирлеге башкарма комитетының структур бүлекчәләреннән аналитик материаллар, чараларның җыелма планы буенча тәкъдимнәр һәм аларның үтәлеше турында мәгълүмат, шулай ук йөкләнгән бурычларны нәтиҗәле үтәү өчен кирәкле башка материалларны сорарга һәм алырга;

үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча мәгълүмат базасы төзергә;

аерым эшләрне башкару өчен хезмәткәрләрне шартнамә нигезендә җәлеп итү турындагы мәсьәләләрне Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы башкарма комитеты җитәкчесе каравына чыгарырга;

билгеләнгән тәртиптә үзара хезмәттәшлекне оештырырга һәм федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук үз компетенцияләренә кертелгән мәсьәләләр буенча оешмалар белән хезмәт язышуын тәэмин итәргә».

1.2. Карарга 2 нче кушымта тексты буенча «Методик рекомендацияләр» сүзләрен тиешле килештәге сүзләр белән алмаштырырга: «Җирле үзидарә органнарында беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча методик тәкъдимнәр (РФ Кораллы Көчләр Генераль штабы начальнигы - РФ Оборона министрының беренче урынбасары тарафыннан 2017 елның 11 июлендә расланган)

2. Әлеге карарны Борискино авылы, Үзәк урамы, 61 йорт; Березовка бистәсе, Үзәк урамы, 16 йорт торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Борискино авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Ж.С.Илалов